# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

"25" ноябрь 2022 ел. №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 25 ноябрендә «Сез 2023 елда Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, 1 төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлар, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган яшәүчегә, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Яңа Шимбер авылы территориясен чистарту, үлән чабу, агач һәм куак кисү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Яңа Шимбер авылы зиратына юллар салу һәм ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Яңа Шимбер авылының урам юлларын кардан чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

Аерым мәсьәләләр буенча экономияләнгән очракта Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 37 (утыз җиде) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 19 (унтугыз) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 19 (унтугыз) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. «Сез 2023 елда Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, 1 төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлар, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган яшәүчегә, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

   - Яңа Шимбер авылы территориясен чистарту, үлән чабу, агач һәм куак кисү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
   - Яңа Шимбер авылы зиратына юллар салу һәм ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
   - Яңа Шимбер авылының урам юлларын кардан чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

   Аерым мәсьәләләр буенча экономияләнгән очракта Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы: Галиәхмәтов Д.М.